КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Кызыл-Мишә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

29.10.2020 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 27 номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2020 елның 29 октябрендә узган гражданнар җыенында "2021 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Кызыл-Мишә торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Кызыл-Мишә торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Кызыл-Мишә торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 238 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 122 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 122 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче Кызыл-Мишә торак пунктында халык җыенын үткән дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.

2. "2021 нче елда Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенә керүче Кызыл-Мишә торак пунктында, яшәү урыны буенча Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең Кызыл-Мишә торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Кызыл-Мишә торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау, карарын кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Тимершык авыл
җирлеге башлыгы А.Х. Хаҗиев